ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
КАРАР

№ 2 14 ноябрь 2023 ел

"Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлегенең Татар Сөнчәлесе авылында
гражданнарның үзара салым чараларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы

Карар итәм:

1. 2023 елның 29 ноябрендә Татар Сөнчәлесе авыл клубы бинасында ТР, Аксубай муниципаль районы, Татар Сөнчеле авылы, Тукай ур., 12 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Татар Сөнчеле авылына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 14 сәгать 00 минутка билгеләнсен.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2024 елда Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Татар Сөнчәлесе авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ,( I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш), алынган акчаларны җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итүгә ,түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы:

Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

• Татар Сөнчәле авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (ташлар сатып алу, кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

Күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территорияләрен төзекләндерүне оештыру

• * Татар Сөнчәле авылы территориясен төзекләндерү (трактор һәм аларга комплектлаучы җиһазлар сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күпләп җыелу урыннарында, стендларда һәм белдерү такталарында элгән килеш игълан итәргә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т.В. Зюзина